| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШЭhЭРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 187 24.12.2015ел

**«Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген һәм торак урыннарны алу турында»**

Күпфатирлы йортта авария хәлендә дип танылган һәм җимерелергә тиешле торак урыннар милекчеләре булмаганга, аларны билгеләнгән вакытка сүтү, Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 10 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 56.3, 56.6 статьясы, «Күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану турында» 2009 елның 11 декабрендәге 28 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов ур., 4йорт адресы буенча урнашкан 16:37:010402:4 кадастр номерлы, гомуми мәйданы 484,19 кв.м. булган җир кишәрлеген муниципаль ихтыяҗлар өчен алу.
2. Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген тартып алуга бәйле рәвештә, милекчеләрдән муниципаль ихтыяҗларны сатып алу юлы белән Спас районы, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы, 4 йорт кануннарда билгеләнгән тәртиптә, кушымта нигезендә, торак урынны тартып алырга.
3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң ун көн дәвамында, күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Спас бүлегенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//htth:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм «Яңа тормыш» район газетасында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

РТ Спас муниципаль районының
Болгар шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Тюленев

ТР Спас муниципаль районы
Болгар шәһәр Башкарма комитетының
2016 елның __ _______ ___ номерлы карарына
кушымта

Болгар шәһәрендәге Хирург Шеронов урамы буенча 4 - нче номерлы йортның муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алу юлы белән алынырга тиешле торак урыннары исемлеге

| № | Торак урыны номеры | Торак бинаның кадастр номеры | Гомуми мәйдан (кв. м) |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 | 16:37:060201:739 | 33,8 |